ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14 апрель, 2023 ел

**РЕШЕНИЕ**
**№28-01**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы, миграция ситуациясе турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәрованың, Россия эчке эшләр Министрлыгының Актаныш районы буенча бүлек җитәкчесе урынбасары - полиция майоры Р.Ф.Басыйровның, Актаныш районы имам-мөхтәсибе Р.Р.Мортазинның милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында миграция хәле турындагы чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, милләтара үзара аңлашуны һәм конфессияара татулыкны саклау, милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең, миграция ситуациясенең торышы турында»гы докладларын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына:

— «2021-2025 елларга Актаныш муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасында каралган чараларны үтәүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елына багышланган чараларны оештыруны, әзерләнгән план нигезендә тәэмин итәргә (Актаныш муниципаль райны Башкарма комитеты җитәкчесенең 12.04.2023 нче ел №ПР-57 карары);

3.1. Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына:

- җирлек Советының чираттагы утырышларында милли мәдәниятне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең, миграция ситуациясенең торышы турындагы мәсьәләне карарга;

- халык арасында уяулыкны һәм оешканлыкны арттыруга, гадәттән тыш хәлләргә әзерлек, мәгълүмат алмашу өлешендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлтелгән аңлату эшләрен оештырырга;

- теркәлмәгән затларның законсыз яшәү ихтималын ачыклау максатында, җирлек территориясендә буш торган йорт биләмәләрен йөреп чыгуны оештырырга.

3.2. Актаныш муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләренә, милек формаларына бәйсез рәвештә, аеруча мөһим объектларның саклануын көчәйтү, югары хәвефлелек, тормышны тәэмин итү, транспорт инфраструктурасы, социаль әһәмиятле объектлар һәм гражданнар күпләп җыела торган объектлар буенча өстәмә чаралар күрергә;

-чит ил гражданнарын эшкә урнаштырганда «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында «Федераль Законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2010 елның 19 маендагы 86-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль Законы нигезләмәләренә таянырга, ул 2010 елның 1 июлендә үз көченә керде.

3.3. Районның дини оешмаларына тәкъдим итәргә:

-гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә үз эшчәнлеген алып барырга;

-дини оешмаларның күчемсез милек объектларына хокукларын документаль рәсмиләштерүне тәэмин итәргә.

3.4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларына, мәгариф учреждениеләренә, иҗтимагый оешмаларына милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә, милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклауга һәм аларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән аңлату, мәгълүмати сәясәт алып барырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Актаныш муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Л.Р.Зарипов**